ГЛАВА
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.01.2020 Балык Бистәсе штп. № 06пг

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә, башка гаскәрләргә, хәрби берләшмәләргә һәм органнарга, шулай ук сугыш вакытына төзелә торган махсус берләшмәләргә мобилизация чорында һәм сугыш вакытында бирелә торган транспорт чараларының әзерлеген тикшерү турында

1996 елның 31 маендагы “Оборона турында” 61-ФЗ номерлы, 1997 елның 26 февралендәге “Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында” 31-ФЗ номерлы, 1998 елның 28 мартындагы “Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында” 53-ФЗ номерлы Федераль законнарны, Россия Федерациясе Президентының 1998 елның 2 октябрендәге 1175 номерлы “Хәрби-транспорт бурычы турында нигезләмә” исемле Указын, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре Генераль штабы Башлыгының 2018 елның 16 октябрендәге 315/2/1002 номерлы күрсәтмәләрен, Үзәк хәрби округ Штаб башлыгының 1918 елның 7 ноябрендәге 1Ч/20/2/583 номерлы күрсәтмәләрен үтәү йөзеннән һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә, башка гаскәрләргә, хәрби берләшмәләргә һәм органнарга, шулай ук сугыш вакытына төзелә торган махсус берләшмәләргә мобилизация чорында һәм сугыш вакытында бирелә торган транспорт чараларының әзерлеген тикшерү максатыннан һәм тарайтылган утырыш карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы Хәрби комиссарына (Ф.А.Ваһаповка) тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 01 мартына кадәр оешмалар җитәкчеләре белән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә, башка гаскәрләргә, хәрби берләшмәләргә һәм органнарга, шулай ук сугыш вакытына төзелә торган махсус берләшмәләргә мобилизация чорында һәм сугыш вакытында бирелә торган транспорт чараларының әзерлеген тикшерү буенча үзара багланыш (элемтә) оештырырга;

- Балык Бистәсе муниципаль районында мобилизацион транспорт ресурсларының барлыгын тикшерү буенча комиссия Планын эшләргә һәм расларга (Кушымта №1);

- техника белән тәэмин итүче оешмаларны тикшерү графигын расларга, транспорт чаралары белән тәэмин итүче оешмаларны тикшерү графигыннан өземтәне билгеләнгән тәртиптә формалаштыручы частьләр адресына җибәрергә (Кушымта №2);.

- комиссиянең эш нәтиҗәләрен транспорт чаралары белән тәэмин итүче оешмаларны тикшерү актларында чагылдырырга;

- 2020 елның 25 июненә кадәр оешмаларда транспорт чараларының техник торышы турында комиссия эшенә анализ ясарга.

2. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә тәкъдим ителә торган мобилизацион транспорт ресурсларының әзерлеген тикшерүне оештыру буенча комиссиясе составын расларга (Кушымта №3)

- тикшерү уздырганда комиссия составына Россия Федерациясе Кораллы Көчләрен техника белән тәэмин итүче оешмаларның документларын эшләү буенча методик рекомендацияләргә таянып эш итәргә (Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты тарафыннан эшләнгән).

3. Мобилизация биреме булган оешмалар җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- мобилизация буенча билгеләнгән транспорт чараларының мобилизацион әзерлеген тикшерү өчен комиссия составын оешма территориясенә керүне тәэмин итәргә;

- күрсәтелгән срокларда ярдәмче комиссия составы тарафыннан тикшерүгә мобилизация буенча тәэмин ителергә тиешле транспорт чараларын әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләргә;

- кирәкле запас частьләр комплекты белән бөтен аталган техниканы комплектлаштырырга;

- аларда махсус җиһазлар урнаштыру өчен әзерлек чаралары үткәрергә;

- транспорт чараларын оешмалар көчләре һәм чаралары белән яңадан җиһазландыруны яки җиһазландырып бетерүне үткәрергә;

- оешманың һәр билгеләнгән транспорт чарасының булуын һәм төзеклеген раслый торган документларын тикшерүгә тәкъдим итәргә (транспорт чарасының паспортын, транспорт чарасын теркәү турында таныклыкны, диагностика карталарын, иминият полюсларын);

- ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгына һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы хәрби комиссарына мәгълүмат биреп тәкъдимнәр әзерләргә;

- һәрбер транспорт чарасының булуын һәм төзеклеген раслый торган документларның күчермәләрен, аларга һәр транспорт чарасының фотоотчетын теркәп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы Хәрби комиссариатына тапшырырга;

-ачыкланган барлык җитешсезлекләрне 2020 елның 30 июненә кадәр бетерүне оештырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы хәрби комиссары Ф.А. Ваһаповка (килешү буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башлыгының
2020 елның 10 гыйнварындагы
06пг номерлы карарына
кушымта №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында мобилизацион транспорт ресурсларының барлыгын тикшерү буенча эш планы

| № п/п | Чаралар исеме | Чараларның үтәлеше өчен җаваплы | Үткәрү датасы |
|---|---|---|---|
| 1. | Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә тәкъдим ителә торган мобилизацион транспорт ресурсларының әзерлеген тикшерү буенча Балык Бистәсе муниципаль районы Советы, Башкарма комитеты һәм оешмалар белән бәйләныш (элемтә) оештыру | Хәрби комиссар Ф.Вәһапов | 2020 елның 1 мартына хәтле |
| 2. | Транспорт чаралары белән тәэмин итүче оешмаларны тикшерү графигын формалаштыручы хәрби частьләр адресына ( графикның аларга кагылышлы өлешен) юллау | СПНО (ППП һәм УМР) АСУ буенча Ю.Никитина | 2020 елның 1 мартына хәтле |
| 3. | Оешмаларда Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә, башка гаскәрләргә һәм формированиеләргә аталган транспорт чараларының барлыгын һәм техник торышын һәм аларның Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә бирелүгә әзерлеген тикшерү. | Ярдәмче комиссия составы | Тикшерү графигы нигезендә |
| 4. | Төзек булмаган, исәпкә алу урыны буенча булмаган очракта транспорт чараларын исемлеккә теркәү | СПНО (ППП һәм УМР) АСУ буенча Ю.Никитина | Зарур булганда |
| 5. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы Хәрби комиссариатының җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан һәр транспорт чарасының барлыгын һәм төзеклеген раслаучы документлар күчермәләрен җыю | СПНО (ППП һәм УМР) АСУ буенча Ю.Никитина | Транспорт чараларын тикшерү уздыру барышында |
| 6. | Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә 2020 елга план-график нигезендә бирүгә | СПНО (ППП һәм | 2020 елның 5 апреленә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | оешмаларның транспорт чараларының әзерлеген тикшерү турындагы мәгълүматларны Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына тапшыру | УМР) АСУ буенча Ю.Никитина | һәм 5 июлена |
| 7. | Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгына мобилизация буенча билгеләнгән транспорт чараларының техник торышы турында мәгълүмат бирү | СПНО (ППП һәм УМР) АСУ буенча Ю.Никитина | 2020 елның 25 июненә кадәр |
| 8. | Барлык техника белән тәэмин итүче оешмалар буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү | Ярдәмче комиссия составы | 2020 елның 25 июненнән 30 июнена кадәр |
| 9. | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты комиссиясе тарафыннан транспорт чараларын Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә бирүгә әзерлеген тикшерү | Хәрби комиссар Ф.Ваhапов, техника белән тәэмин итүче оешмаларның җитәкчеләре | 2020 елның 20 июленнән 24 енә хәтле |

Балык Бистәсе муниципаль
районы  Башлыгының
2020 елның  10 гыйнварындагы
06пг   номерлы карарына
кушымта  №2

Гаскәрләрне комплектлаштыру өчен аталган техника белән
тәэмин итүче оешмаларны
тикшерү графигы

| № п/п | Автохуҗалык исеме | Карау датасы |
|---|---|---|
| 1. | “КУЛОН-АГРО” ҖЧҖ | 22.03.2020 |
| 2. | “БАЛЫК БИСТӘСЕ ҮЗӘК РАЙОН ХАСТАХАНӘСЕ” ДАССУ | 25.03.2020 |
| 3. | “ЛОГОС” ҖЧҖ | 07.04.2020 |
| 4. | “КАМА-ПЛЮС” КҖ | 15.04.2020 |
| 5. | “БАЛЫК БИСТӘСЕ ПАССАЖИР АВТОТРАНСПОРТ ПРЕДПРИЯТИЕСЕ” ҖЧҖ | 21.04.2020 |
| 6. | “ БАЛЫК БИСТӘСЕ АГРОХИМСЕРВИС” ҖЧҖ | 25.05.2020 |

Балык Бистәсе муниципаль
районы Башлыгының
2020 елның 10 гыйнварындагы
06пг номерлы карарына
кушымта №3

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә тәкъдим ителә торган мобилизацион транспорт ресурсларының әзерлеген тикшерүне оештыру буенча комиссия

СОСТАВЫ

Ярдәмче комиссия рәисе – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы хәрби комиссары Ваһапов Фәрит Әдип улы;

комиссия әгъзалары:

хәрби комиссариат бүлеге (ППП һәм УМР) башлыгы (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы, үзидарәлек) – Шакиров Илшат Рәфкать улы;

хәрби комиссариатның АСУ буенча бүлек (ППП һәм УМР) башлыгының өлкән ярдәмчесе (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы, үзидарәлек) – Никитина Юлия Юрьевна;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе – Мәгыйзов Марс Венер улы;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башлыгы – Камалиев Илмир Ирек улы.